ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 31.10.2023 **КАРАР**
1686

Спорт мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләргә спорт разрядлары биргән өчен Алабуга муниципаль районы тренерларын бүләкләү турында

Алабуга муниципаль районының иң яхшы тренерларына спорт разрядлары биргән өчен адреслы ярдәм күрсәтү максатларында: Спорт мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләргә: «Атказанган спорт мастеры», «Халыкара класслы спорт мастеры», «Спорт мастеры», «Спорт мастерлыгына кандидат» спорт разрядлары биргән өчен Алабуга муниципаль районының иң яхшы тренерларына адреслы ярдәм күрсәтү максатларында, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 1. Спорт мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләргә спорт разрядлары биргән өчен Алабуга муниципаль районы тренерларына бер мәртәбә түләү бирү турында теркәлгән Нигезләмәне расларга (1 нче кушымта).

2. Алабуга муниципаль районы тренерына бер мәртәбә түләү билгеләү критерийларын расларга (2 нче кушымта).

3. Алабуга муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының агымдагы финанславы хисабына Алабуга муниципаль районы тренерларына бер тапкыр бирелә торган түләүләрне финанслауны тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Н.Д. Курамшинга йөкләргә.

Җитәкче Э.Р. Әхмәдиева

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН
ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ
СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП
Сертификат: 30C33C67746B0C8EA9DE00B6707B1433
Владелец: Ахмадеева Эльмира Равильевна
Действителен с 19.10.2023 до 11.01.2025

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
31.10.2023 1686 номерлы
карарына 1 нче кушымта

**Спорт мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләргә спорт разрядлары биргән өчен Алабуга муниципаль районы тренерларын бүләкләү турында Нигезләмә**

1. Спорт мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләргә спорт разрядлары биргән өчен Алабуга муниципаль районы тренерларын бүләкләү (алга таба - бүләкләү) Алабуга муниципаль районының иң яхшы тренерларына бер мәртәбә адреслы ярдәм күрсәтү максатыннан гамәлгә ашырыла.
2. Тренерга бүләкләүне билгеләү Алабуга муниципаль районы спорт мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләргә спорт разрядлары биргәндә гамәлгә ашырыла:

«Атказанган спорт мастеры»,
«Халыкара класслы спорт мастеры»,
«Россиянең атказанган спорт мастеры»
«Спорт мастерлыгына кандидат».

3. Бүләкләү Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты финанславы хисабына бер тапкыр гамәлгә ашырыла.
4. Бүләкләүләрне раслау өчен тренерлар кандидатлары исемлеге Алабуга муниципаль районының спорт мәктәпләре тәкъдимнәре буенча төзелә.
5. Бүләкләү алуга кандидат булып Алабуга муниципаль районының муниципаль бюджет спорт мәктәбе тренеры була ала.
6. Бүләкләүгә кандидатларны тәкъдим итү өчен Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының спортны үстерү секторына түбәндәге документларны тапшырырга кирәк:

6.1. Алабуга муниципаль районы тренерын бүләкләүгә дәгъва итүче турында мәгълүмат (әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымта);

6.2. Спорт мәктәбе тәрбияләнүчесенә (спортчысына) спорт исеме бирелү турында Татарстан Республикасы, Россия Федерациясе Спорт министрлыгы боерыгының күчермәсе;

6.3. Тренер паспортының күчермәсе;

6.4. Россия Федерациясе территориясендә яшәү урыны буенча салым органында (ИНН) тренерны исәпкә кую турында таныклык күчермәсе;

6.5. Индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслый торган һәм тренерның индивидуаль шәхси счетының иминият номеры турында белешмәләр булган документның күчермәсе;

6.6. Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык.

Алабуга муниципаль районы спорт мәктәбе директоры (җитәкчесе) тәкъдим итүне (үтенечнамәне) әзерли һәм имзалый.

Спорт мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләргә
спорт разрядлары биргән өчен
Алабуга муниципаль районы
тренерларын бүләкләү турындагы
Нигезләмәгә 1 нче кушымта

Алабуга муниципаль районы тренерын бүләкләүгә дәгъва кылу турында белешмәләр

| Дәгъвачының (тренерның) фамилиясе, исеме, атасының исеме . | Туган көне (чч.мм.г.) | Адресы | Спорт мәктәбенең аталышы | Спорт разряды бирү турында спорт мәктәбендә тәрбияләнүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме | Спорт разряды бирү турында мәгълүмат (спорт төре, разряд, бирелү датасы) |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

Өстәмә белем бирү учреждение җитәкчесе _______________/________/
фамилиясе, исеме, атасының исеме

(имза)

Мөһер урыны

Спорт мәктәпләрендә
тәрбияләнүчеләргә спорт разрядлары
биргән өчен Алабуга муниципаль
районы тренерларын бүләкләү
турындагы Нигезләмәгә 2 нче
кушымта

Спорт мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләргә спорт разрядлары биргән өчен Алабуга муниципаль районы тренерларына бер мәртәбә түләү билгеләү өчен критерийлар

| № | Спорт разрядының аталышы<br>. | Бүләкләү күләме, сумнарда |
|---|---|---|
| 1. | Атказанган спорт мастеры | 50 000, 00 |
| 2. | Халыкара класслы спорт мастеры | 40 000, 00 |
| 3. | Россия спорт мастеры | 30 000, 00 |
| 4. | Спорт мастерлыгына кандидат | 20 000, 00 |

Лист согласования к документу № 1686 от 31.10.2023
Инициатор согласования: Мусина Е.А. Главный специалист организационного отдела
Согласование инициировано: 06.12.2023 16:00

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Ахмадеева Э.Р. | | Подписано<br>06.12.2023 - 16:00 | - |